МИНИСТЕРСТВО
ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

09.10.2024 № 80

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара һәм төбәкара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына карата таләпләр билгеләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законны һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында» федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы чикләрендә уза торган даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның халыкара һәм төбәкара маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларының 4 һәм аннан югарырак класслы экологик характеристикаларга туры килүе турындагы таләп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты бүлеге башлыгына:

әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгән әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы чикләрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның төбәкара маршруты буенча автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган транспорт чараларының экологик характеристикаларына карата таләп билгеләү турында» 2022 елның 12 августындагы 249 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Х.Садыйковка йөкләргә.

Министр Ф.М.Хәнифов